ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 август, 2024 ел № 36/5

«2025- 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Рәисе Указы проектын килештерү хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карарының 43 пунктында билгеләнгән тәртип нигезендә,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

«2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Рәисе Указы проектын килештерергә (кушымтада).

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
36/5 Карарына кушымта
26 август, 2024 ел

Проект

**2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ номерлы күрсәтмәсе нигезендә **карар бирәм**:

1. Расларга:

2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын (1 нче кушымта);

2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик (максималь) индекслары зурлыгын нигезләүне (2 нче кушымта).

2. Әлеге Указ кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Рәисе Указына
1 нче кушымта
_______ , 2024 ел № ___

2025 - 2027 елларга
Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары

| № т/б | Муниципаль берәмлек | Чик индекслар (процентларда) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2025 - 30.06.2025 | 01.07.2025 - 31.12.2025 | 01.01.2026 - 30.06.2026 | 01.07.2026 - 31.12.2026 | 01.01.2027 - 30.06.2027 | 01.07.2027 - 31.12.2027 |
| 1 | Яр Чаллы шәһәре | 0 | 15,0 | 0 | 11,0 | 0 | 11,0 |

Татарстан Республикасы
Рәисе Указына
2 нче кушымта
_______ , 2024 ел № ___

2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик (максималь) индекслары зурлыгын нигезләү

| № т/б | Муниципаль берәмлек | Муниципаль берәмлекләрдә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик (максималь) индекслары зурлыгын нигезләү |
|---|---|---|
| 1 | Яр Чаллы шәһәре | Муниципаль берәмлекләрдә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең үзгәрүенең билгеләнгән чик (максималь) индексларын (алга таба – чик индекслар) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары белән килештерү турындагы белешмәләр: «2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Рәисе Указы проектын килештерү хакында» 2024 елның____________ ______________ номерлы Шәһәр Советы Карары.<br>Билгеләнгән чик индекслар күләменә йогынты ясаган сәбәпләр һәм факторлар турында аңлатма: «Чаллы су каналы» ҖЧҖ инвестиция программасы.<br>Чик индекс күрсәткечә туры килә торган коммуналь хезмәтләр җыелмасы һәм төзекләндерү тибы: салкын су белән тәэмин итү (суүткәргече, үзәк яисә җирле канализациясе һәм үзәкләштерелмәгән кайнар су белән тәэмин итү системасы (абонент кайнар суны мөстәкыйль әзерли торган корылмалар һәм җайланмалар, шул исәптән индивидуаль җылылык пунктлары) булган, биеклеге 12 каттан артып киткән һәм аларга карата төзекләндерү таләпләре югары булган фатир тибындагы торак йортлар,)<br>су агызу (суүткәргечле, үзәк яисә җирле канализацияле һәм үзәкләштерелмәгән кайнар су белән тәэмин итү системалы абонент кайнар суны мөстәкыйль әзерли торган корылмалар һәм җайланмалар, шул исәптән индивидуаль җылылык пунктлары) булган, биеклеге 12 каттан артып |

| | | |
|---|---|---|
| | | киткән һәм аларга карата төзекләндерү таләпләре югары булган фатир тибындагы торак йортлар, җылылык белән тәэмин итү (күпфатирлы һәм үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системалары булган торак йортлардагы торак урыннарны җылыту), электр белән тәэмин итү (шәһәр торак пунктлары, электр плитәләре белән җиһазландырылган йортлар), каты коммуналь калдыклар белән эш итү.<br>01.07.2025 башлап коммуналь хезмәтләргә тарифларның фаразланган күләмнәре һәм аларның үзгәрү темплары: электр белән тәэмин итү – 4,60 сум/кВт/сәг (12,2 процент), салкын су белән тәэмин итү – 34,54 сум/куб.м (15,5 процент), су агызу – 29,38 сум/куб. м (26,2 процент), җылылык белән тәэмин итү – 2551,23 сум/Гкал (10 процент), каты коммуналь калдыклар белән эш итү – 604,51 сум / куб. м (10 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану күләмнәре һәм (яисә) нормативлары (ККК туплау нормативлары), җир кишәрлегеннән һәм ишегалды корылмаларыннан файдаланганда коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану нормативлары: индекс кулланыла торган коммуналь хезмәт күрсәтүләр җыелмасының һәм күләменең үзгәрешсезлеге принцибыннан чыгып исәпләнә.<br>Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрүе билгеләнгән чик индекска тигез булган халык саны – 38959 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 7,3 процент, республикадагы өлеше – 0,97 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләменең үзгәрүе республика буенча билгеләнгән индекска тигез (яисә азрак) булган халык саны - 0 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 0 процент, республикадагы өлеше – 0 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләменең республика буенча билгеләнгән индекстан зуррак, әмма республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк билгеләнгән чик индекстан кимрәк (яисә тигез) республика буенча тайпылыш зурлыгыннан артыграк булмаган халык саны – 0 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 0 процент, республикадагы өлеше - 0 процент).<br>Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрүе республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк булган халык саны – 515523 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 96,6 процент, республикадагы өлеше – 12,9 процент).<br>Республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк чик |

| | | |
|---|---|---|
| | | индекс билгеләү нәтиҗәсендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләүнең гомуми суммасы июльдән декабрьгә кадәр ай саен 46 525,42 мең сум тәшкил итәчәк.<br>01.07.2026 башлап коммуналь хезмәтләргә тарифларның фаразланган күләме һәм аларның үзгәрү темплары: электр белән тәэмин итү – 5,67 сум/кВт/сәг (5 процент), салкын су белән тәэмин итү – 38,34 сум/куб.м (11 процент), су агызу – 35,84 сум/куб. м (22 процент), җылылык белән тәэмин итү — 2653,28 сум/(Гкал 4 процент), газ белән тәэмин итү – 8,42 сум/куб. м (3 процент), каты коммуналь калдыклар белән эш итү-628,69 сум/куб. м (4 процент).<br>Коммуналь хезмәтләр җыелмасы һәм чик индекс күрсәткече туры килә торган төзекләндерү тибы: салкын су белән тәэмин итү (сuүткәргечле, үзәк яисә җирле (чокыр) канализацияле һәм кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән системасы (абонент мөстәкыйль рәвештә кайнар су әзерли торган корылмалар һәм җайланмалар, шул исәптән индивидуаль җылылык пунктлары) душ белән җиһазландырылган 1 500 мм дан 1 700 мм га кадәр озынлыктагы ванналы фатир тибындагы торак йортлар), су агызу (сuүткәргечле, үзәк яисә җирле (чокыр) канализацияле һәм кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән системасы (абонент мөстәкыйль рәвештә кайнар су әзерли торган корылмалар һәм җайланмалар, шул исәптән индивидуаль җылылык пунктлары) душ белән җиһазландырылган 1 500 мм дан 1 700 мм га кадәр озынлыктагы ванналы фатир тибындагы торак йортлар), җылылык белән тәэмин итү (җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы һәм торак йортларда торакларны җылыту), электр белән тәэмин итү (шәһәр торак пунктлары, газ плитәләре белән җиһазландырылган йортлар), газ белән тәэмин итү (челтәр газы), каты коммуналь калдыклар белән эш итү.<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану күләмнәре һәм (яисә) нормативлары (ККК туплау нормативлары), җир кишәрлегеннән һәм ишегалды корылмаларыннан файдаланганда коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану нормативлары: индекс кулланыла торган коммуналь хезмәт күрсәтүләр җыелмасының һәм күләменең үзгәрешсезлеге принцибыннан чыгып исәпләнә.<br>Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрүе билгеләнгән чик индекска тигез булган халык саны – 470396 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – |

| | | |
|---|---|---|
| | | 88,1 процент, республикадагы өлеше – 11,8 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләменең үзгәрүе республика буенча билгеләнгән индекска тигез (яисә азрак) булган халык саны - 0 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 0 процент, республикадагы өлеше – 0 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләменең республика буенча билгеләнгән индекстан зуррак, әмма республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк билгеләнгән чик индекстан кимрәк (яисә тигез) республика буенча тайпылыш зурлыгыннан артыграк булмаган халык саны – 0 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 0 процент, республикадагы өлеше -0 процент).<br>Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрүе республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк булган халык саны – 515523 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 96,6 процент, республикадагы өлеше – 12,9 процент).<br>Республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк чик индекс билгеләү нәтиҗәсендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләүнең гомуми суммасы июльдән декабрьгә кадәр ай саен 31 255,69 мең сум тәшкил итәчәк.<br>01.07.2027 башлап коммуналь хезмәтләргә тарифларның фаразланган күләме һәм аларның үзгәрү темплары: электр белән тәэмин итү – 5,90 сум/кВт/сәг (4 процент), салкын су белән тәэмин итү – 42,43 сум/куб.м (10,7 процент), су агызу –43,44 сум/куб. м (21,2 процент), җылылык белән тәэмин итү — 2759,41 сум/(Гкал 4 процент), газ белән тәэмин итү – 8,67 сум/куб. м (3 процент), каты коммуналь калдыклар белән эш итү-653,83 сум/куб. м (4 процент).<br>Коммуналь хезмәтләр җыелмасы һәм чик индекс күрсәткече туры килә торган төзекләндерү тибы: салкын су белән тәэмин итү (суүткәргечле, үзәк яисә җирле (чокыр) канализацияле һәм кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән системасы (абонент мөстәкыйль рәвештә кайнар су әзерли торган корылмалар һәм җайланмалар, шул исәптән индивидуаль җылылык пунктлары) душ белән җиһазландырылган 1 500 мм дан 1 700 мм га кадәр озынлыктагы ванналы фатир тибындагы торак йортлар), су агызу (суүткәргечле, үзәк яисә җирле (чокыр) канализацияле һәм кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән системасы (абонент мөстәкыйль рәвештә кайнар су әзерли торган корылмалар һәм җайланмалар, шул исәптән индивидуаль җылылык |

| | | |
|---|---|---|
| | | пунктлары) душ белән җиһазландырылган 1 500 мм дан 1 700 мм га кадәр озынлыктагы ванналы фатир тибындагы торак йортлар), җылылык белән тәэмин итү (җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары булган күпфатирлы һәм торак йортларда торакларны җылыту), электр белән тәэмин итү (шәһәр торак пунктлары, газ плитәләре белән җиһазландырылган йортлар), газ белән тәэмин итү (челтәр газы), каты коммуналь калдыклар белән эш итү.<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану күләмнәре һәм (яисә) нормативлары (ККК туплау нормативлары), җир кишәрлегеннән һәм ишегалды корылмаларыннан файдаланганда коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану нормативлары: индекс кулланыла торган коммуналь хезмәт күрсәтүләр җыелмасының һәм күләменең үзгәрешсезлеге принцибыннан чыгып исәпләнә.<br>Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрүе билгеләнгән чик индекска тигез булган халык саны – 470396 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 88,1 процент, республикадагы өлеше – 11,8 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләменең үзгәрүе республика буенча билгеләнгән индекска тигез (яисә азрак) булган халык саны - 0 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 0 процент, республикадагы өлеше – 0 процент).<br>Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләменең республика буенча билгеләнгән индекстан зуррак, әмма республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк билгеләнгән чик индекстан кимрәк (яисә тигез) республика буенча тайпылыш зурлыгыннан артыграк булмаган халык саны – 0 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 0 процент, республикадагы өлеше -0 процент).<br>Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрүе республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк булган халык саны – 515523 теркәлгән кеше (муниципаль берәмлектәге өлеше – 96,6 процент, республикадагы өлеше – 11,9 процент).<br>Республика буенча билгеләнгән индекстан артыграк чик индекс билгеләү нәтиҗәсендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләүнең гомуми суммасы июльдән декабрьгә кадәр ай саен<br>34 330,21 мең сум тәшкил итәчәк. |